# Минем кадерле әнием

**Хадиулина Э.З.**
Башлангыч сыйныф укытучысы, 1 кв.категория
МБОУ «Югары Сон урта гомуми
белем бирү мәктәбе”

# Максат:



*Әнкәй безгә бәхет теләп,*
*Яратып баккансың да,*
*Гөлләр итеп үстергәнсең*
*Гомерең бакчасында.*

*Давыл килсә күкрәгеңне,*
*Куйгансың каршысына,*
*Хәзер дә бит безнең өчен*
*Әзер син барысына.*



Җылы наз ул, әнием,
синдә генә,
Иркә сүзләр- синең
телдә генә,
Матур хисләр, уйлар
йөрәгеңдә,
Изге синең, әнием,
теләгең дә.




***Сез гөл- әни, гөл-апа,***
***гөл-сеңел...***
***Сез кагылган җырлар***
***бәхетле...***
***Сез булганга, дөнья***
***мәңге матур,***
***Шагыйрь күңеле***
***татлы, тәхетле.***

Әни сүзен тыңлаган,
үзенең кыланышлары
белән аны
рәнҗетмәгән, ана
киңәшләре һәм
ризалыгы белән
яшәгән кеше генә
бәхетле була.



**Ташлама, әнкәй, ташлама**
**Мине изге догаңнан,**
**Ташласаң изге догаңнан,**
**Мин бәхетле була алмам...**



*Безнең өчен күргән кайгылардан*
*Әниләребез яшен түкмәсен,*
*Әниләрнең түккән күз яшьләре*
*Каргыш булып безгә төшмәсен.*

*Балалары өчен хәсрәтләрдән*
*Акшарланып чәче агарган.*
*Йөрәгебез бозга әйләнсә дә,*
*Бер җылы сүз табыйк аңарга!*

*Исәнлектә хөрмәт итми калсак,*
*Алар ташлап киткәч соң була,*
*Бервакытта вөҗдан кичермәслек,*
*Гомерлеккә сагыш, моң була.*

*Үсеп җиткәч, инде кеше булгач,*
*Әниләрне ташлап китмәгез!*
*Ташлап китеп, картлык көннәрендә*
*Сез аларны ятим итмәгез.*

*Әниләрнең бөтен мәхәббәте,*
*Бөтен мәрхәмәте балада.*
*Аналарга дигән җан җылысы*
*Адашып йөрмәсен далада*



Бөек хөрмәт безнең анабызга,
Чәчәк сибик аның юлына,
Безнең өчен бөтен гомерен биргән
Тик ул гына, бары ул гына.

Һәрбер кеше аңа башын иеп
Узган чакта шуннан юллары.
АНА дигән шушы бөек исем
Торсын йолдызлардан югары!